| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 305

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы, 2021 елның 19 ноябрендәге 115 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 231 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 272 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 612-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маендагы 495 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (2021 елның 3 июнендәге 73 номерлы, 2021 елның 19 ноябрендәге 115 номерлы, 2022 елның 15 декабрендәге 231 номерлы, 2023 елның 30 мартындагы 272 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 19 нчы статьяның 3 нче өлешендә «бер ай һәм өч айдан артык» дигән сүзләрне «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» дигән сүзләр белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми Порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**